Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының
“Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем бирү
муниципаль бюджет учреждениесе

# *Көз бүләге*

(“Көз” бәйрәме уңаеннан мәктәпкә әзерлек төркеме белән
үткәрелгән бәйрәм кичәсе)




**Төзеде:** тәрбияче Исламова А.Г.
Музыка җитәкчесе: Сафиуллина Л.А.

Ямаширмә, 2021

**Балалар кулларына яфраклар тотып бию башкаралар.**



**Альяна:** Тәрәз артында Көз кызы,
Яфраклар белән уйный.
Беркемнән дә сорап тормый,
Моңсу сәламнәр юллый.

**Рәсим:** Яфракларын җиргә сибә,
Җилләр белән шаярып.
Паркларда, бакчаларда
Йөртә кулымнан тотып.

**Ясминә:** Бар бизәкләрен күрсәтә,
Кышны искә төшерә.
Җайлап кына, иплэп кенә,
Салкын көннәр китерә..

**Муса:** Кара, кара, җиргә кара,
Яфраклар келәм булган.
Табигатьнең һәр фасылы,
Матурлык өчен туган.

**Сәйдә:** Җәйнең кошлары сайраса,
Кышның кар-бураннары..
Язын гөрләвекләр акса,
Көзнең үз планнары.

**Нияз:** Урман-кырлар, болыннарны
Бизи ул төрле төскә.
Яфракларын җыеп куйган
Көтә безне биюгә.

**Ясминә:** Салмак кына , ашыкмыйча,
Көзләр килә илемә.
Һәр агачның үз төсе бар,
Аны Көз генә белә.

**Айнур:** Кошкайларны тәртип белән
Җылы якка озата.
Ә аннары әкрен генә,
Болытларын елата.

**Самира:** Яңгырлар явып торса да,
Сөйкемле Көз, тәмле Көз.
Әйдә кил, безгә тизерәк,
Без сине бик көтәбез!

**Барысы бергә:** Көз, Көз, Көз, Без сине бик көтәбез!

**Алып баручы.** Нишләп килми Алтын көз,
Безгә вакыты җитмиме?
Эшләре дә бик күп инде,
Әллә юлны белмиме?
Һич аптырап тормыйк әле,
Көз турында җырлыйк әле,
Ул, әлбәттә, ишетер,
Безгә бәйрәмгә килер.

**Җыр: "Яфрак бәйрәме"**

***Музыкага КӨЗ КЫЗЫ керә.***

**Көз.** Ишеттем мин сезнең җырны,
Тиз таптым килер юлны.
Яратам балаларны,
Дус күрәм мин аларны.
Сентябрьгә, Октябрьгә,
Ноябрьгә мин хуҗа.
Җәй кызы ул минем сеңлем,
Кар кызы апам була.

**Көз.** Сез көзләрне яратасыз,
Мин аны белә идем.
Бар эшләремне калдырып,
Димәк, юкка килмәдем.

**Алып баручы.** Көз кызы, син бераз ял ит,
Безнең белән бәйрәм ит.

**Көз.** Кунакка сезне чакырам,
Могҗизалы урманга.
Юк, юк, көзге матурлыкны
Күрик башта бакчада.
Җиләк-җимеш, яшелчәләр
Бүген әллә нишләгән.
Тәмле бакча Корольлеге,
Әкияткә әйләнгән.

**Нәзирә:** Әй, дусларым, гаҗәп монда,
Корольлек бакчасында.
Яшелчә, җиләк-җимешләр
Принцесса, принцларга
Әйләнгәннәр барысы да.

***Фанфара яңгырый. Карбыз белән Кабак (кыз, малай) тантаналы рәвештә чыгалар, түгәрәк әйләнеп троннарга килеп утыралар.***




**Көз кызы.** Тәмле бакча биләмәсенең Короле- Карбыз Икенче.
***Карбыз тора, баш ия, ышынычлы тавыш белән сөйли.***
**Карбыз.** Мин йомры һәм бик зур,
Дәрәҗәле һәм матур.

**Көз кызы.** Кабак булган Королева, мәрхәмәтле һәркемгә.
**Кабак.** Кояшны бик яратканга,
Кояш төсендә үзем.
Алтын кояш нурларыдай
Минем матур көлмәгем.
**Көз.** Ә кызлары Кишерсылу,
Коеп куйган кәртинкә.
Бер генә дә тик тормый ул,
Җырлый-бии һәм тегә.



**Кишер *(кылтаеп).*** Мин бик шаян Кишерсылу,
Мода белән киенәм.
Чәчләремне көн дә тарыйм,
Матур булып күренәм?
**Көз кызы.** Әйе, Кишерсылу үсеп җиткән,
Әти-Карбыз башына бер уй төшкән.
**Карбыз.** Әй, әнисе Кабак бикәм,
Кызны кияүгә бирик.
**Кабак.** Кая болай ашыгасың
Яшь бит әле, үстерик.
**Карбыз.** Һәрбер эшнең үз вакыты,
Мин интернетка куям.
Кызыма дигән кияүләр,
Бик тиз килер, ышанам.
**Көз кызы.** Интернетта хәбәр чыкты,
Башланды ыгы-зыгы.
Кияү егетләре уйма,
Бер минутта җыелды.
***Маршка Граф Кыяр чыга.***
**Кыяр.** Мин гади кыяр түгел,
Граф минем титулым.
Бераз артык үскәнмен,
Ә шулай да көчлемен.
Мин акыллы, мин эшчән
Һәркемгә ярый беләм.
Байлыгым чиктән ашкан,
Ел да уңышлар мулдан.
Бик шәп кияү егете,
Ашап карагыз мине.
***Карбызга кыяр бирә.***
**Карбыз.** Ай-яй, бу бит биетә,
Аяк тыпырдап китә.
Әйдә, җаным, син дә бас,
Биеп алыйкчы бераз.
**Көз кызы.** Барыбыз да биибез, Көе килми, димибез.
**Түгәрәктә парлы бию.**
**Музыкага ПОМИДОР чыга.**
**Помидор.** Мин күркәм, затлы Помидор,
Мин итальян, мин синьор.
Буем озын булмаса да,
Йөзләрем көлеп тора.
Кигән кызыл кафтаным да
Ялтырап, килешеп тора.
Мин әле бик таланлы да,
Дирижёр оркестрда.
Кишерсылу, синең өчен

Чыгыш ясыйбыз монда.

**КҮҢЕЛЛЕ ОРКЕСТР.**

***Музыкага вак-вак атлап БОРЧАК керә.***

**Борчак.** Мин кузаклы, тәмле Принц
Борчак Патшаның улы.
Әтиемнең җире бик күп,
Һәм дә бик күп байлыгы.
Кишерсылу,
Бу сандыгым—
Сиңа булсын бүләгем,
Күңелсез булган чакларда
Күңелеңне күтәрсен.
Менә аның ачкычы,
Чүт-чүт кенә борасың,
Килеп чыгар борчаклар,
Алар белән җырларсың.



**Кишерсылу.** Кая, кая, борып карыйм,
Бу сандыкның серен ачыйм.

***Кишерсылу сандыкны ача, Тылсымлы музыкага вак-вак атлап-йөгереп кызлар-борчаклар чыгалар.***

**1 Борчак.** Без күңелле борчаклар,
Матур-матур курчаклар.

**2 Борчак.** Безне яңгыр үстерә,
Яңгыр безгә көч бирә.

**3 Борчак.** Без яңгырны зурлыйбыз,
Аны мактап биибез.

**Зонтиклар белән бию башкаралар.**



**Карбыз.** Кызым минем, принцессам,
Егетләр бит ничава.
Кайсы сиңа бик ошый,
Әйдә берәрсен сайла.

***“Кияүләр” тезелеп басалар, Кишерсылу аларга карап сөйли.***

**Кишерсылу.** Белмим, кайсын сайларга,
Берсенең буе кыска, (борчакка)
Берсе кып-кызыл битле. (помидорга)
Монысы әтием төсле. (кыярга)
Берсенә дә күзем төшми,
Йөрәгем дөп-дөп типми.

**Кабак (еламсырап).** Сайланып торган буласың,
Кияүсез бит каласың.

***Музыкага СУГАН керә.***

**Суган.** Ачы, тәмле кыякларым
Мин беренче бакчада.
Мин граф, маркиз да түгел,
Ә баш ияләр барсы да.
Мин, Суган, синең күршең
Күптән сине күзәтәм,
Без икебез пар килгәнбез,
Сиңа гына өйләнәм.

**Суган тезләнеп Кишернең кулын үбә.**

**3 кияү**. Үзе ачы, үзе зәһәр,
Кулын тотсаң еларсың,
Юк байлыгы, бездән дә шәп,
Бер кияү дә тапмассың.

**Кишерсылу.** Ә нәрсәгә кирәк байлык**,**
Елмаюы ни тора.
Мин Суганны сайлап алам,
Егет шушындый була.

Хәерчегә Суганга.

***Суган белән Кишер күңелсез генә барып утыралар,***

***Металл яңгырашлы музыка ишетелә.***

**Кабак.** Куркыныч җил исәме?
Тагын кияү киләме?

***САРУТ ПАТША КЕРӘ.***

**Сарут.** Мин чүп үләннәр патшасы,
Сарут була исемем,
Беркем мине җиңә алмый,
Тамырларым нык минем,
Ишеттем сезнең бакчада,
Бер кәләш үсә икән,
Зифа буйлы, бик әдәпле,
Ә мин, кияү бер дигән.




**Кишер.** Юк инде, чүп үләнгә чыкканчы,
Ялгыз торганың яхшы.

**Сарут.** Яхшылык белән бармасаң,
Явызлык белән алам. **(кулыннан тарта).**

**Кишер.** Әй, егетләр, булышыгыз,
Чүп үләннән коткарыгыз.

**Кияүләр чыгалар.** Бик сугышыр идек тә,
Безнең форма бозыла. (килеш-килбәт)

**Кабак (кияүләрне куа).** Әй, куркаклар, югалыгыз,
Кем бар анда, чыгыгыз, кызымны коткарыгыз.

**Суган ашыгып чыга.** Үзем киләм, коткарам,
Укларым белән атам.
Патша булсаң чык бирегә,
Бергә-бер көрәшергә.

***Суган белән Сурат биюе.***



**Көз кызы.** Шундый озак күрәштеләр,
Ярый әкият кыска,
Суган Суратны юк итте,
Йолкып атты бик оста.
Аннан җитәкләшеп алар,
Кыз өенә кайттылар,
Король белән Королева
Әйбәт каршы алдылар.

***Суган белән Кишерсылу Карбыз белән Кабакка баш ияләр.***



**Суган.** Кызыгызның кулын сорыйм,
Рөхсәт бирегез безгә.
**Кишер.** Әти-әни, мин Суганны
Сайладым гомерлеккә.
**Карбыз.** Без риза, булсын сезнеңчә,
Музыканы кушыгыз.
Безнең шатлык, бик зур шатлык
Сез безгә кушылыгыз.
**Кабак.** Әй, икегез, икегез,

Икегезнең битегез.
Икегез дә пар килгәнсез,
Тигез гомер итегез.

**Көз кызы.** Менә шулай тәмле бакча,
Гөрләтеп туй ясады,
Биемәгән, уйнамаган
Бер кеше дә калмады.



**Парлы бию.**

**Балалар белән “Картошка” уены уйныйбыз.**



**Малайлар “Тракторист” биюен башкаралар.**



**Көз кызы.** Менә нинди зур тамаша,
Сезнең белән карадык.
Үзебез дә әкиятнең
Чын геройлары булдык.
Сезнең белән саубуллашам,
Бер елдан күрешербез,
Көзнең иң тәмле җимеше,
Алмалар күчтәнәчем.

**Алып баручы**. Көз кызы, сиңа зур рәхмәт. Синең белән безгә бик күңелле булды. Балалардан...

**Балалар.** Зур рәхмәт!

**Камил:** Наступила осень. Пожелтел наш сад,
Листья на берёзе золотом горят.
Не слыхать веселых песен соловья,
Улетели птицы в дальние края.

**Алинә:** Как огнём горит вся улица,
Листья спорят с ветерком.
Даже хочется зажмуриться,
Так красиво всё кругом!

**Айнур:** Осень скоро попрощается,
Подарив наряд цветной,
Ведь не зря её красавицу,
Называют золотой!

**ЖЫР: “Осень”**

***Соңгы куплетта Көз кызы кулын болгап, балалар яныннан үтеп чыгып китә.***



